ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 25.02.2025

**К А Р А Р** № 245

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе төзү турында» 2024 елның 26 мартындагы 316 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 һәм 42.12 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында» 2015 елның 20 мартындагы 177 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе төзү турында» 2024 елның 26 мартындагы 316 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе составы» дип аталган 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Комиссия составыннан Э.Р. Ихсанованы чыгарырга;

1.2. Комиссия составыннан Р.Ф. Хәкимуллинны чыгарырга;

1.3. Комиссия составыннан И.В. Муринаны чыгарырга;

1.4. Комиссия составына кертергә: Т.В. Антонованы - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ баш белгечен, комиссия секретарен;

1.5. Комиссия составына кертергә: Р.Ф. Хәкимуллинны - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесен, комиссия рәисен;

1.6. Комиссия составына кертергә: Т.И. Мифтаховны –- «Поволжье» АКИ СРО вәкилен;

1.7. Комиссия составына кертергә: О.М. Ивановaны – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча (Казан шәһәре буенча) идарәсенең №2 күчемсез милеккә хокукларны дәүләт кадастр исәбе һәм дәүләт теркәве бүлеге башлыгы урынбасарын;

2. Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе төзү турында» 2024 елның 26 мартындагы 316 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 22 февралендәге 240 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин